| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ЧУТЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЧҮТИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«19» сентябрь 2025 ел Чүти ав. № 2

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Чүти авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгын сайлау турында .

«Гавами хакимият бердәм системасында җирле үзидарәне оештыру гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Чүти авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 42 статьясы, яшерен тавыш бирү нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе утырышының 2 нче беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлеге Советы КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чути авыл җирлеге Башлыгы, Чүти авыл җирлеге Советы Рәисе итеп 6 нче Кыр бермандатлы сайлау округыннан депутат Әхмәтшина Гөлнур Зөфәр кызын сайларга.
2. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясының 1 өлеше, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Чүти авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 41 статьясының 5 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Чүти авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе итеп Әхмәтшина Гөлнур Зөфәр кызын билгеләргә.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталында һәм «Кайбыч таңнары»-«Кайбицкие зори» газетасында бастырып чыгарырга, http://chuteev-kaybici.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Чүти авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар кабул ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Чүти авыл җирлеге Советы утырышында рәислек итүче

Н.А.Галкина